УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ СОСТОЯНИЕМ САМОХОДНЫХ МАШИН И ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫНА КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

«14» февраль 2014г. №01-05/30-пр

Казан ш.

Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең тракторларга, үзйөрешле юл-төзү машиналарына һәм башка төр машиналарга һәм аларга тагылмаларга дәүләт хезмәтен күрсәтү, алар өчен (Хәрби Көчләр һәм Россия Федерациясенең башка гаскәрләре машиналарыннан тыш) дәүләт теркәве билгеләрен бирү буенча Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең 28.05.2013 ел №01-05/85-пр боерыгы белән расланган Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ
ТЕРКӘЛДЕ
МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ЗАРЕГИСТРИРОВАНО
«03» 03.2014 г.
ТЕРЧ №
РЕГИСТРАЦИОННЫЙ 2234

Алданрак чыгарылган актны законнарның дәүләт хезмәтен күрсәтү өлкәсендәге таләпләренә туры китерү максатларында

**БОЕРЫК БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсенең тракторларга, үзйөрешле юл-төзү машиналарына һәм башка төр машиналарга һәм аларга тагылмаларга дәүләт хезмәтен күрсәтү, алар өчен (Хәрби Көчләр һәм Россия Федерациясенең башка гаскәрләре машиналарыннан тыш) дәүләт теркәве билгеләрен бирү буенча Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче бүлекнең «Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең стандарты» 2.12 пунктындагы «30» һәм «40» саннарын тиешле рәвештә «15» һәм «15» саннарына алмаштырырга;

«Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, шулай ук алардагы вазыйфаи затларның, дәүләт хезмәткәрләренең карарларын һәм гамәлләрен (гамьсезлеген) судка кадәр (судтан тыш) шикаять кылу тәртибе» турындагы 5 нче бүлекне түбәндәге эчтәлектәге 5.9 пункты белән тулыландырырга:

«5.9. Шикаятьне карау барышында яисә карау нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яисә җинаять кылу составының билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вазыйфалары белән вәкаләтләнгән вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына юллый».

2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Начальник Р.Р. Зиатдинов